**Шигърият докторы**

(Нил Юзиевның тууына – 80 ел).

Күңелем белән, Тукай әйтмешли, картаймасам да, минем дә инде яшем шактый. Җиде дистәдән артык якты дөньяда яшәү вакытында миңа бик күп кешеләр белән аралашырга, йөзәрләгән мөгаллимнән гыйлем-тәрбия алырга, тереклек-мәгыйшәт серләрен өйрәнергә туры килде. Болар арасында Нил Гафур улы Юзиев (10.01.1931 – 11.09.1996) аеруча мөхтәрәм урынны били. Мин университетта 1959 – 1964 елларда белем алдым. Шушы вакытта Нил абый безне укытты, студентлык төркемебезнең кураторы да булды. Мин аның җитәкчелегендә бер курс эше һәм “Сюжет мәсьәләләре” темасына диплом яздым. Студент елларында дөнья күргән мәкалә-рецензияләрем дә Нил абыйның хәер-фатыйхасы белән укучыларга иреште. Ул мине Мәскәүгә Бөтендөнья әдәбият институтына аспирантурага җибәрергә бик тырышты. Әмма, матди сәбәпләр аркасында, мин Сарман якларына эшкә китеп бардым. Анда да арабыз өзелмәде, очрашкалап тордык: Дамира ханым (1937 – 24.10.2010) белән Нил абыйның матур гаиләсендә берничә мәртәбә кунак булганымны да хәтерлим. Бу мөхтәрәм остазым мине әдәбият фәне өлкәсендә ныклап эшләргә гел чакырып торды. Һәм, ниһаять, Нил абый һәм Хатыйп ага Госман тырышлыклары аркасында, мин 1967 елның ноябрендә университетның татар әдәбияты кафедрасында укытучы булып эшли башладым. Инде менә 43 елдан артык бу вазыйфаны башкарып киләм.

Әгәр дә мин гыйльми-педагогик һәм иҗтимагый эшләрдә билгеле бер уңышларга ирешкәнмен икән, монда, әлбәттә, Нил абыйның да роле зур. Озак еллар буе бергә эшләү, аралашу вакытында мин һәрчак аның хәергаһлыгын, ярдәмен тоеп тордым. Кылган игелекләре өчен мин һәрчак бу мөхтәрәм остазыма рәхмәтле.

Шундый бер вакыйга истә калган. 1993 елда минем “Татарская литература и восточная классика ...” исемле монографиям нәшер ителде. Ул тиз арада гыйльми-мәдәни җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәя алды, аның хакында дистәләгән мәкалә-рецензияләр дөнья күрде. Шунда Нил абый

минем бу китапны Татарстанның Дәүләт премиясенә тәкъдим итү мәсьәләсен күтәреп чыкты. Һәм аның игелекле кулы белән башланган бу эш тиз арада гамәлгә дә ашты.

Нил абый студентларның иң яраткан укытучыларыннан берсе иде. Ул үз шәкертләренә һәрвакыт ихтирами мөнәсәбәттә торды, аларны укуга, иҗатка дәртләндерә, канатландыра белде, дәресләрен җанлы, мавыктыргыч итеп уздыра иде. Аның аеруча шигъриятне тирәнтен аңлап, эченә кереп, матурлыгын тоеп аңлатуы безгә ошый иде. Бу зат сүз сәнгатендәге, әдәбият фәнендәге яңалыклар белән даими танышып барды, аларны студентларга җиткерергә тырышты. Ул бигрәк тә яшь каләм әһелләрен тәрбияләүгә зур игътибар бирде. Һәм гомумән Нил абый әдипләр белән тыгыз мөнәсәбәттә торды. Аның сүзенә, киңәш-теләкләренә мәртәбәле олуг язучылар да, әдәбиятка яңа аяк баскан яшьләр дә колак сала иде.

Нил Гафур углы 1931 елның 10 январенда Башкортостанның Яңавыл районы Ямады авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Аларның өендә әдәбият-сәнгать культы хакимлек итә. Киләчәктә олуг галим һәм шагыйрь булып танылачак, икесе дә Тукай премиясе лауреатлары булачак Нил һәм Илдар (3.01.1933 – 21.12.2004) Юзиевлар әнә шундый әдәби - мәдәни мохитта үсәләр. Ямадыдан ерак кына түгел Күрдем авыл мәктәбендә 1943-1951 елларда татар-башкортның гаять талантлы шагыйре Әнгам Атнабаев мөгаллимлек кыла, тирә-юньдәге яшь каләм әһелләрен туплый, иҗатка дәртләндерә. Мөгаен, ике бертуган Юзиевкә дә “Атнабай сабаклары” йогынты ясагандыр. Ямады урта мәктәбен тәмамлагач, Нил һич икеләнүсез 1948 елда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлагач, яшь тәнкыйтьчене татар әдәбият кафедрасында аспирантурада калдыралар. Биредә ул 1953-1956 елларда укый. 1958 елда “Муса Җәлил поэмалары” темасына кандидатлык диссертациясе яклый. (Фәнни җитәкчесе – Х.Госман, рәсми оппонентлары - Кирәй Мәргән һәм Роберт Бикмөхәммәтов). Аның хезмәте патриот-шагыйрь иҗатын өйрәнүдә җитди, мөһим адым дип бәяләнә.

1956-1960 елларда Нил Юзиев “Совет әдәбияты” журналында әүвәл тәнкыйть бүлеге мөдире, аннан җаваплы секретарь булып эшли.

1960 елдан башлап ул Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында – укытучы, бераздан доцент. 1974 елның 25 апрелендә Н.Юзиев “Татар совет поэзиясенең поэтикасы” темасына диссертация яклап, бераздан филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. Шунысын да искәртик: аның диссертация яклавы татар гыйльми-мәдәни тормышында зур бер вакыйга булды. Нәкъ шушы көннәрдә аңа, докторлык хезмәтенең төп эчтәлеген тәшкил иткән “Шигырь гармониясе” (КДУ нәшр., 1972. – 221 б.) һәм “Хәзерге татар поэтикасы” (К.: Татар.кит.нәшр., 1973. – 352 б.) китаплары өчен, әдәбиятчылардан беренче булып, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде.

1975 елда яңа гына доктор булган талантлы галимне Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына әдәбият секторы мөдире итеп күчерәләр. Биредә ул муеннан эшкә чума: төрле гыйльми проектлар гамәлгә ашырыла, исәпсез-хисапсыз чаралар уздырыла. Болар арасында 6 томлык татар әдәбияты тарихын язу, чыгару төп урынны били. Н.Юзиев аның план-проспектын төзүдә, авторларны барлауда, кулъязмаларны тикшерүдә, томнарны китап итеп чыгаруда төпкә җигелеп тарта. Күптомлыкның шактый гына бүлек-бүлекчәләрен ул турыдан-туры үзе дә яза.

Н.Юзиев 1986 елдан үлеменә кадәр шул ук Институтның кулъязмалар һәм текстология бүлеге белән җитәкчелек итте. Авыруына да карамастан, ул бу елларда рухи мирасыбызны барлауда, гыйльми өйрәнүдә, күп кенә ядкярләрне укучыларга җиткерүдә чын мәгънәсендә фидакарьләрчә эшләде. Аның җитәкчелегендә нәшер ителгән “Әдәби мирас” сериясендәге җыентыклар әдәбият фәненең офыкларын киңәйтте. Университет белән дә араны өзмәде: дәүләт имтихан комиссиясендә дә катнашты, гыйльми хезмәтләргә рецензияләр язды, махсус курслар алып барды.

Күрәбез: Н.Юзиевның эшчәнлеге гаять күпкырлы һәм төрле. Бу аның язма мирасында да ачык күренә. Галимнең дистәләгән китаплары [“Тормыш поэзиясе” (1961), “Традицияләр яңарганда” (1966), “Муса Җәлил поэмалары” (1969), “Сәнгатьчә матурлык һәм осталык” (1969), “Әдәбият хәзинәләре” (1978), “Шигърият дөньясы” (1981), “Татар шигыре” (1991), “Мир поэта: о творчестве Х.Такташа, М.Джалиля, Х.Туфана, С.Хакима” (1987) һ.б.], йөзәрләгән мәкаләләре бар. Аларның исем-атамалары гына да Н.Юзиев мирасының асылын, төп юнәлешләрен күзалларга ярдәм итә. Шунысы да мәгълүм булсын: галим эшчәнлеге хакында Г.Рамазанов, Н.Хисамов, Т.Галиуллин, С.Сафуанов һәм кайбер башка билгеле затларның уңай эчтәлекле язмалары бар.

Н.Юзиевне татар сүз сәнгатенең бүгенгесе һәм үткәне дә, башка әдәбиятлар белән бәйләнешләре дә, теоретик проблемалары да, гамәли мәсьәләләре дә, проза, драма, поэзия төрләре дә кызыксындыра. Ул рухи мираска, әдипләрнең иҗатына, язма истәлекләргә әдәп белән, аларның кадер-кыйммәтен тоеп якын килә. Галим башка халыклардагы гыйльми-эстетик яңалыклар, казанышлар белән даими танышып бара, аларны үз язмаларында иҗади, үзебезнең мәдәни хәзинәләребезгә игътибар һәм ихтирамны киметмичә файдалана, Н.Юзиев эшчәнлегендә, ничектер, теоретик һәм гамәли башлангычлар табигый кушылып бара, ул реаль чынбарлыктан аерылмый, төрле измнарга, теоретизмнарга бирелми.

Галимнең эшчәнлеге никадәр колачлы булса да, ул, нигездә, XX йөз әдәбиятының, тагын да төгәлрәк әйткәндә, төп фигуралары Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, Хәкимнәр булган узган гасыр шигъриятенең белгече, докторы иде. Галим бу өлкәдә судагы балык кебек иркен һәм оста хәрәкәт итә. Ул XX йөз татар шигъри сүз сәнгатенең асылын, төп юнәлешләрен, кыйммәтен, матурлыгын меңеллык әдәбиятта тоткан урынын билгеләргә омтыла һәм шактый дәрәҗәдә моңа ирешә дә. Галим шигъриятне системалы өйрәнүнең матур үрнәкләрен бирде. Аның фикеренчә, шагыйрь иҗатын, аның әсәрләрен аерым-аерым гына түгел, бер-берсе белән үзара мөнәсәбәттә, рухи

тормыштагы башка күренешләр белән бәйләнештә караганда гына тиешенчә аңлап һәм бәяләп була. Шулай ук ул шигъриятнең сәнгатьнең башка төрләр белән багланышта торуын да ассызыклый.

Н.Юзиев – татар әдәбият фәнендә иҗат лабораториясен, иҗат психологиясен өйрәнүнең дә күренекле белгече. Ул төрле ысуллар кулланып (әдипләр белән әңгәмә; анкеталар тутыру; вариантларны өйрәнү һ.б.), иҗади процессның гаять катлаулы һәм каршылыклы булуын күп төрле мисаллар ярдәмендә яктыртуга ирешә. Галим шигырьнең, ана карынындагы бала кебек, яралуын, үсешен, ахыр чиктә билгеле бер шәкел алып тууын яктырта. Аның иҗат процессында уй-ният, ассоциация, хыял һәм кайбер башка фактор-күренешләрнең нинди роль уйнауларын яктыртуы белгечләр өчен генә түгел, киң катлам укучылар өчен дә кызыклы.

Фән өчен факт-мәгълүматлар, чыганаклар сулый торган һава кебек зарури. Н.Юзиев бу хакыйкатьне тирәнтен аңлап, кульязма һәм басма нөсхәләрне туплауга, архив материалларын өйрәнүгә җитди игътибар итте. Аның кандидатлык диссертациясен язганда М.Җәлилгә кагылышлы мәгълүматларны ныклап өйрәнүе - шуның күркәм бер мисалы. Галим бу юнәлештәге эшен алга таба да уңышлы дәвам иттерде. Аның 1962 елда Барда районы Каенавылында Мөхәммәдьярның “Төхфәи мәрдан” поэмасының борынгы бер нөсхәсен табуы фәндә югары бәяләнде.

Бу уңай белән шунысын да искәртү урынлы булыр. Нил абый, гәрчә ул, нигездә, соңгы дәвер әдәбияты белгече булса да, гарәп язулы мирас, Шәрык белән дә бәйләнеш мәсьәләләре белән даими кызыксынып килде. Шуңа күрә аның кульязмалар бүлегенә мөдир булып килүе дә мантыйкый күренеш иде. Бу өлкәдә белгечләр хәзерләүне дә күз уңында тотты. Үзенең улын Ленинград университетының гарәп бүлегендә укытуы да очраклы түгел. Айдар Юзиев – татар рухи мирасын, Шәрык фәлсәфәсен, аеруча Мәрҗани хезмәтләрен өйрәнү буенча зур белгеч, философия фәннәре докторы, Татарстан Язучылар Берлеге әгъзасы. 2000 елда ул “Нил Юзиев – шигъри җанлы акыл иясе” (анда “Мирасханә ядкәрләре” дип исемләнгән бүлек тә

бар) (320 б.) исемле җыентык чыгарды. Бу истәлек-хатирәләр китабы галимнең үзен танып-белүдә генә түгел, әдәбият тарихын, гыйльми-мәдәни тормышны өйрәнүдә дә мөһим чыганак.

Н.Юзиев татар язма мирасын туплау һәм өйрәнүнең теоретик һәм методологик якларын фәнни эшкәркән галим дә. Бу яктан аның “Әдәбият чыганаклары белеме” китабы гаять зур гыйльми һәм гамәли әһәмияткә ия.

Н.Юзиев язмаларында әдәбият фәне һәм әдәби-тәнкыйть башлангычлары, ничектер, кушылып бара. Ул тәнкыйтьче буларак чыгыш ясаганда, еш кына әдәбият тарихына, теориясенә, эстетикага да мөрәҗәгать итә, алардагы казанышларны үз язмаларында уңышлы файдалана. Аның мирасында XX йөзнең күпчелек әдип-шагыйрьләре теге яки бу дәрәҗәдә телгә алына, аларның әсәрләре тикшерелә. Болар арасында, мәшһүр затлар белән беррәттән, яшь, әдәбиятка яңа басучылар да бар. Шунысы күңелле: Нил абыйны Рәдиф Гаташ, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зиннур Мансуров, Зөлфәт һәм галимнең элеккеге студентлары үзләренең остазлары дип саныйлар. Фән дөньясында да турыдан-туры Нил абый катнашында тәрбияләнгән галимнәр шактый (Р.Салихов, Н.Вәлиев, Ф.Ганиева, А.Садекова, И.Еникеев, С.Мамытов, Н.Мурадымов һ.б.).

Н.Юзиев үзенең хезмәттәшләре, остазлары хакында да бик эчтәлекле мәкаләләр, очерк-портретлар язды. Болар арасында М.Гайнуллин, Х.Госман, Г.Халит, Г.Кашшаф һәм башка галимнәр бар.

Н.Юзиев озак еллар буе җанлы әдәби һәм гыйльми хәрәкәттә, иҗтимагый-мәдәни тормышта актив катнашып килде. “Тукай җәмгыяте”нә нигез салды, аның беренче рәисе булды. Татарстан Фәннәр Академиясенең тәүге мөхбир-әгъзаларыннан берсе итеп сайланды. Язучылар Берлегенең идарә әгъзасы да булып торды. Мәктәпләр өчен дәреслек-әсбаплар, программалар төзүдә катнашты. Бу олы җанлы, инсани рухлы зат 1996 елның 11 сентябрендә 65 яшендә якты дөньядан китеп барды. Аны соңгы юлга

озатуга гаять күп кеше җыелуны әле дә хәтерлим. Кабере – Биектау районының Сасмак авылы зыяратында.

Филология фәннәре докторы, Тукай бүләге лауреаты, “Татарстанның атказанган фән эшлеклесе” (1981), күренекле галим, тәнкыйтьче, педагог Нил Гафур углы Юзиев фән, әдәбият мәгариф үсешенә үзеннән зур өлеш кертте, рухи тормышыбызда тирән эз калдырды. Аның мирасы бүгенге көнебез өчен дә бәһаләп бетергесез хәзинә.

Хатыйп Миңнегулов
27.12.2010.